*Батыршина Г.Г. (РИИ, Казань)*

# ТАТАР ТЕЛЕННӘН ТҮГӘРӘК ДӘРЕСЛӘРДӘ СӨЙЛӘМ ТЕЛЕН ҮСТЕРҮ (КАЮМ НАСЫЙРИ ИҖАТЫ МИСАЛЫНДА)

Бөтендөнья татар конгрессы һәм Татарстан Республикасы Хөкүмәте ярдәме белән, Россия Ислам институты гыйльми советы карары нигезендә 2015 нче елның августында татар теле һәм милли мәдәният кафедрасы ачылды. Кафедра оештыруның төп сәбәпләре булып, бүгенге көн мөселман дин эшлеклеләрен әзерләүдә татар теленең мөһимлеген күрсәтү, студентлар арасында тәрбия эшен алып бару, аларда татар телен тирәнтен өйрәнүгә теләк тудыру. Кафедра эшчәнлегенең төп максаты – татарча сөйләшә белүче, татар әдәби телендә иркен аралаша торган имамнар әзерләү. Соңгы вакыттагы вәзгыять, ягъни республикабызда җомга көннәрендә хотбәләрнең бары тик татарча гына сөйләнергә тиешлеге безгә карата булган җаваплылыкны тагын да арттыра. Шулай итеп, татар телен өйрәнү өчен, аудитор сәгатьләр арта, ул түгәрәк кысаларында да өйрәнелә башлый.

Бу елдан башлап, телне өйрәнү тагын да нәтиҗәлерәк булсын өчен, түгәрәк дәресләренә йөрүче студентлар ике төркемгә бүленде (башлап өйрәнүчеләр һәм дәвам итүчеләр). Соңгыларында исә татар теленең грамматик төзелешен, аның кулланылыш үзенчәлекләрен аралашу процессында дөрес кулланырга өйрәтү, шулай ук сөйләм күнекмәләрен тагын да камилләштерү, ягъни туган телнең бар нечкәлекләрен тоеп, аңлап эш итү төп

максатлардан санала. Татарстан Республикасында татар теленең дәүләт теле булуын, аның татар халкының рухи мирасын буыннан-буынга җиткерү, шулай ук милләтара мөнәсәбәтләрне җайга салучы чара икәнлеген дә студентларга җиткерү – алга куелган бурычларның берсе. Шулай итеп, төп игътибар телне милли-мәдәни яссылыкта өйрәтүгә юнәлдерелә. Бу үз чиратында дәрестә, тел материалларыннан тыш, халыкның милли йолалары, гореф-гадәтләре, халык авыз иҗаты әсәрләрен өйрәнү аша алып барыла. Милли үзенчәлекләрне чагылдырган текстлар белән эшләү, язучы әсәрләре белән танышу, татар сөйләм әдәбе нормаларын үзләштерү дә зур әһәмияткә ия.

Татар теленнән түгәрәк дәресләрдә бәйләнешле сөйләм үстерүдә беренче юнәлеш – вәгазь текстлары белән эшләү. Дәрескә аерым бер темага багышланган вәгазь алына. Укып чыгып, аннан аңлашылмаган сүзләр, катлаулырак җөмләләр өстендә эш (чөнки бу төркемдә дә телне төрле дәрәҗәдә белүчеләр бар) һәм тәрҗемә башкарыла. Соңыннан сорауларга җавап бирү, фикер алышу һәм студенттан шул вәгазьне сөйләтү. Икенче юнәлештә сөйләм телен үстерү, алда әйтеп кителгәнчә, әдәби әсәрләр, милли йола, гореф-гадәтләр, халык авыз иҗаты әсәрләре, милләтебезнең танылган шәхесләре иҗаты белән танышу аша алып барыла.

Әлеге мәкаләдә сүз күренекле галим, мәгърифәтче Каюм Насыри эшчәнлегенә багышлап үткәрелгән дәрес турында бара. Ул белем алу, гыйлемлелек темасын яктырта.

Әлбәттә, дәрес башында К. Насыйри шәхесе, тәрҗемәи хәле сөйләнелә: «Каюм Насыйри – танылган мәгърифәтче, педагог, тәрҗемәче, этнограф, телче – XIX гасырның II яртысында үзенең барлык гомерен, гыйлемен, сәләтен фән һәм белем, мәдәният һәм тәрәккыять таратуга, шул рәвешчә, халыкка хезмәт итүгә багышлый» [1, с. 3]. Кыскача гына биографиясе белән танышудан, студентлар аның укымышлы гаиләдән булуы, мәдрәсә тәмамлавы, гарәп, фарсы, рус телләрен яхшы белүе, Духовный семинариядә татар теле укытуы, татар балаларына рус телен өйрәтү мәктәбен ачуы турында мәгълүмат алалар. ««Шура»дагы истәлекләргә караганда, мулла булырга әзерләнүче татар яшьләре дә, урыс телен өйрәнергә дип, аның янына йөриләр. Ләкин 1876 елда рус булмаган мәктәпләр буенча инспектор В.В.Радлов белән уртак тел таба алмаган К.Насыйри

мөгаллимлек гамәлен туктата һәм барлык гомерен фән һәм язучылык эшенә багышлый» [2, б. 5].

«Каюм Насыйри – киңкырлы гыйлем иясе» дигәндә, галимнең энциклопедик эшчәнлеге хакында сөйләнелә.

Каюм Насыйриның фәнни һәм әдәби эшчәнлеге XIX гасыр урталарында башланып китә. Киң карашлы галим фәнни белемнәрнең төрле өлкәләренә үзеннән лаеклы өлеш кертә. Бер яктан – Көнчыгыш мәдәниятен, икенче яктан – Европа фәнни агымнарын яхшы белүе, күпкырлы әзерлекле галим булуы Насыйрига XIX йөздә татар халкы алдында торган мөһим проблемаларны тирәнтен һәм һәрьяклап бәяләргә мөмкинлек бирә. Мәгърифәтченең тикшеренү нәтиҗәләре ул нәшер иткән хезмәтләрдә чагылыш таба [6, с. 14]. Үзе исән чагында ук К.Насыйриның педагогика, тел гыйлеме, матур әдәбият, фольклор һ.б. фән тармакларыннан кырыкка якын китабы басылып чыга.

Дәрестә галимнең һәр өлкәдәге эшчәнлеге яктыртыла, хезмәтләре, кулъязмалары күрсәтелә. Аеруча матур әдәбият өлкәсендәге хезмәтләренә игътибар ителә.

Мәгърифәтче галимнең иң күләмле хезмәтләреннән берсе – «Фәвакиһел җөләса фил-әдәбият» китабы. Урта гасыр әдәп фәне жанрында язылган. 1880 елда «Кырык бакча» исеме астында әлеге әсәрнең кыскартылган варианты басыла. Кырык бүлектән торган бу хезмәттә кеше тормышы һәм эшчәнлегенә турыдан-туры кагылышы булган мәсьәләләр яктыртыла, теге яки бу халәттә нишләргә кирәклеге хакында киңәшләр бирелә.

Дәреснең темасына туры китереп, студентларга әлеге хезмәттән гыйлем турындагы берничә хикәят тәкъдим ителә.

«Пәйгамбәр галәйһиссәлам әйтте: «Өммәтемнең һәлак булуы ике нәрсәдәндер: мал җыю һәм, гыйлем өйрәнмичә, надан калудадыр. Гыйлем – йозактыр, сөаль – ачкычтыр: сорашу һәм сөйләшү белән гыйлем ачыладыр. Берәү кечкенә чагында гыйлем өйрәнмәсә, зур булгач, алга чыкмас, ягъни гыйлем арттыра алмас. Бер ел гыйлем өйрәнү ике ел гыйбадәт кылудан хәерлерәктер. Әдәпнең җимеше – гакылны үстерү, гыйлемнең җимеше – изге гамәле. Бәндәгә дөньяда бирелгән нәрсәләрнең артыграгы хикмәттер вә ахирәттә рәхмәттер» [4, с. 23].

«Пәйгамбәр галәйһиссәламнән бер кеше сорады: «Йә Расүлулла, кайсы гамәл изгерәктер?», – диде. Пәйгамбәр галәйһиссәлам әйтте: «Аллаһы Тәгаләне

белмәк изгерәктер», – дип өч мәртәбә кабатлады. Ул кеше әйтте: «Йә Расүлуллаһ, мин гамәлдән сорадым, син гыйлемнән хәбәр бирәсең», – диде. Пәйгамбәр галәйһиссәлам әйтте: «Гыйлем белән сиңа аз гамәл дә файда кылыр, надан булсаң, сиңа күп нәрсә дә файда кылмас», – диде [4, с. 22].

«Имам Әбү Йосыф әйтте: «Бервакытны углым вафат булды. Имам Әгъзамның гыйлем мәҗлесеннән мәхрүм каламын дип куркып, җеназасына чыкмадым», – диде. Әй угыл, дәрескә ябыш. Дәрес уку – җимеш агачы утырту кебектер. Берәү дәрес укырга озак ялкауланса, нәфесен мәшәкать чиктермәсә, гыйлем алган булмас» [4, с. 23].

«Ибн Габбас разыйаллаһу ганһүдән сорадылар: «Нинәрсә белән син бу кадәр гыйлем дәрәҗәсенә ирештең?», – диделәр. Ибн Габбас әйтте: «Соручы тел белән, белүче калеб белән вә түземле остаз белән», – диде» [4, б.24].

«Пәйгамбәр галәйһиссәлам әйтте: «Гыйлем өйрәнегез, ул – Аллаһы Тәгаләә каршында изге вә сөекле эштер». Кирәк – дөнья өчен, кирәк – ахирәт гамәле хосусында булсын, бары да – гыйлем. Хәтта иң түбән дәрәҗәсе, чабата ясый белү – ул да гыйлем булыр.

Гыйлем сәбәпле хәләлне хәрамнан аера беләсең. Гыйлем оҗмах юлын күрсәтә. Курку вакытында юаныч була. Ялгыз вакытта иптәш була. Сиңа шатлык юлын ача, михнәт вә кайгы юлын бикли. Дусларың янында, гыйлемлек сәбәпле, хөрмәт күрәсең. Дошманнарың катында гыйлемлек бер корал кебек була. Гыйлемлек сәбәпле, изгеләр дәрәҗәсенә ирешәсең. Олугларга вә падишаһларга таныш буласың. Аллаһы Тәгаләне таныйсың. Шәригатьне беләсең. Яхшы ашыйсың, яхшы эчәсең. Бары да гыйлем аркасында. Бер кеше гыйлем ишетү өчен өйдән чыкса, аңа бер фәрештә һәрдаим ярдәмче булыр. Берәү вафат булып, язган китаплары, каләме, кара савыты үзеннән соң икенче бер гыйлем әһеленә мирас булып калса, ул кешегә оҗмах белән сөенеч бирәләр». («Кырык бакча»дан) [5, с. 302].

Күргәнебезчә, бу хикәятләр һөнәри үзенчәлекләрне күздә тотып сайланган. Алга таба әлеге текстлар өстендә эш башкарыла. Иң элек, текст укытучы тарафыннан сәнгатьле итеп укыла (тыңлап аңлау). Аннан бу эш студентларга тапшырыла. Бер-бер артлы сүзлек эше, җөмләләр төзү, сөйләү, ягъни бәйләнешле сөйләм төзү өчен, җирлек әзерләнә.

Текст өстендә эшләү барышында искергән яисә бүгенге көн укучысына таныш булмаган сүзләр ачыклана. Мәсәлән, сөаль – сорау, мәхрүм калу –

нәрсәне дә булса ала алмый калу, михнәт – газап, гыйлем әһеле – галим, белүче һ.б.

Сөйләмне баетуда, фикерне тагын да ачыграк, үтемлерәк итүдә, кабатлаулардан котылу өчен дә, синонимнарның әһәмияте зур. Текстларда кайбер сүзләрнең синонимнарын табу биреме тәкъдим ителә: (гыйлем – белем, белем алу, гыйлем эстәү, уку; бәндә – кеше, инсан, адәм, зат; надан – акылсыз, фикерсез, гыйлемсез, белемсез һ.б.; мал – мөлкәт, байлык һ.б., кайгы – хәсрәт, газап һ.б.).

Шулай итеп, студентлар, әлеге хикәятләрне анализлап, фикер алышуга күчә. Дәпестә «Гыйлем дөнья малыннан кыйммәтлерәк, ул ике дөньяда да бәхет чыганагы булып тора, нинди генә шартларда да гыйлем алырга тырышырга кирәк» дигән нәтиҗә ясала.

Милләтебезнең мәгърифәтле булуын, һәрвакыт аң-белемгә тартылуын халык авыз иҗаты әсәрләрендә дә күрәбез. Бу уңайдан, темага бәйле рәвештә,

шәкертләр үзләре табып килгән мәкальләр белән таныштыра, аларның мәгънәләре ачыклана. Мәсәлән: Белем алу – энә белән кое казу; Гамәлсез гыйлемдә файда юк; Җирнең нуры – кояш, кешенең нуры – гыйлем; Тышыңны кием белән бизә, эчеңне – гыйлем белән һ.б.

Өйгә эш итеп, сөйләм телен үстерүнең тагын бер чарасы буларак, «Гыйлем алу – пәйгамбәрләрдән калган мирас» темасына инша язу бирелә.

Алдагы дәресләрдә К . Н а с ы й р и н ы ң «Әбугалисина», «Җаваһирел хикәят» әсәрләре белән танышу күздә тотыла.

«Илаһи ният кылдым гыйлем үгрәнмәккә, белмәгәнемне белмәк өчен, вә белмәгәннәргә үгрәтмәк өчен, вә шәригатьне тергезмәк вә дин исламны бакый кылмак өчен» – әнә шундый сүзләр белән бөек галим үзенең һәр изге эшен башлаган. Һәр хезмәтен «халкым өчен», «халкыма файда булсын» дип яза. К. Насыйри татар халкын үз традицион мәдәнияте нигезендә заман таләбенә якынайтуны, заманча шәхес тәрбияләүне үз эшчәнлегенең төп максаты итеп билгели һәм шул юлда гомеренең ахыранача хезмәт куя. Татар теленнән түгәрәк дәресләрдә сөйләм телен үстерүдә бөек галимебез иҗаты, һичшиксез, әһәмиятле һәм ул өйрәнелергә тиеш.

Әдәбият:

1. Батыршина Г.Г. Каюм Насыйриның лексикографик эшчәнлеге / Г.Г.Батыршина. – Казан: КДАТУ нәшр., 2007. – 171 б.

2. Гайнетдинов М. Каюм Насыйри: шәхес һәм иҗат / М. Гайнетдинов // Каюм Насыйри. Сайланма әсәрләр. – Казан: Татар кит. нәшр., 2003. – Б. 3-9.

3. Насыйри К. Сайланма әсәрләр. 4 томда, 1 том / К. Насыйри. – Казан: Татар. кит. нәшр., 2003. – 368 б.

4. Насыйри К. Сайланма әсәрләр. 4 томда, 2 том / К. Насыйри. – Казан: Татар. кит. нәшр., 2004. – 400 б.

5. Насыйри К. Сайланма әсәрләр. 4 томда, 4 том / К. Насыйри. – Казан: Татар. кит. нәшр., 2006. – 400 б.

6. Шәймәрданов Р.Х. Габделкаюм Насыйри иҗаты һәм эшчәнлегенең бүгенге көндә әһәмияте / Р. Х. Шәймәрданов // Материалы региональной научно-практической конференции, посвященной 190-летию со дня рождения Каюма Насыри. – Казань, 2015.